РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ МОНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГОПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.12. 2023 ел № 112

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2021 елның 8 октябрендәге 44 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 статьяның 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- 6 статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталындаhttp://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru " Монашево авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Монашево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф.Иосифов